РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
НУРЛАТСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
ГЛАВА ТИМЕРЛЕКСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ТИМЕРЛЕК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | Чуаш Тимерлеге ав. | **КАРАР**

«11 » октябрь 2024 ел                                                  № 1

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Чуаш Тимерлеге авыл җирлегендә гражданнар җыенында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының «Тимерлек авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 23 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Тимерлек авыл җирлеге башлыгы

КАРАР ИТТЕ:

1. 2024 елның 24 октябрендә 11 сәгать 00 минутта Чуаш Тимерлеге авылы, Совет урамы, 58нче йорт адресы буенча кибет янында Нурлат муниципаль районы Тимерлек авыл җирлеге Чуаш Тимерлеге авылының Совет урамында 1-99, 1-10, 1-3нче йортларда, Лесная урамында, Совет тыкрыгында яшәүче гражданнар өчен үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенының беренче этабын уздыруны билгеләргә.

2. 2024 елның 25 октябрендә 17 сәгать 00 минутта Чуаш Тимерлеге авылы, Центральная урамы, 3нче йорт адресы буенча мәктәп янында Нурлат муниципаль районы Тимерлек авыл җирлеге Чуаш Тимерлеге авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча Үзәк урамында 1-33, 1-14, 1-9нчы йортларда, Лесхоз, Нурлат урамнарында яшәүчеләр өчен гражданнар Җыенының икенче этабын уздыруны билгеләргә.

3. Чуаш Тимерлеге авылында яшәүчеләрнең исемлеген сайлау тәртибе халык җыенын үткәрү өчен территориаль билге буенча башкарырга.

4. Гражданнар Җыенының этапларын үткәрү һәм оештыру Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Тимерлек авыл җирлеге башлыгы һәм башкарма комитеты тарафыннан тәэмин ителә.

5. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне раcларга:

«Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Тимерлек авыл җирлегенең Чуаш Тимерлеге авылы территориясендә теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 1 гр инвалидларыннан, балачак инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол калган хатыннарыннан, студентлардан тыш, 2025 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Тимерлек авыл җирлеге Чуаш Тимерлеге авылы торак пункты чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту».

«РИЗА» «КАРШЫ»

6. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга (игълан итәргә) һәм Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында http://nurlat.tatarstan.ru, бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Чуаш Тимерлеге авылы мәгълүмат стендларында халык җыены этапларын үткәрү датасына кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча урнаштырырга.

7. Әлеге карар басылып чыккан (халыкка игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Тимерлек авыл җирлеге башлыгы В.И. Гаврилов